# 1938-1953 нче еллар.

1938 нче елның сентябреннән Кадыбашта җидееллык мәктәп оештырыла. Аның директоры Яппаров Габдулла, завучы Сабирҗанов Габделхәй була. 1930 нчы елны Яппаров Габдулла авыл читенә чыгарып дәүләт хисабына яңа мәктәп салдыра башлый. Төзү эшенә үз проекты белән махсус техник Красный Бордан килә. Мәктәп салуда барлык авыл халкы катнаша. Кадыйров Хаҗимәрдән җитәкчелегендә урман эшлиләр, агач ташыйлар. Нәҗмиев Мулламухамәт бераз эшләтүгә җитәкчелек итә. Габбасов Якуп столяр эше буенча бригадир була. Шулай ук төзү эшләрендә Нәҗмиев Мулланур, Садыйков Нурмөхәмәт һәм башкалар эшли. Балчык эше, фундамент казу, баганалар утырту, түшәм җәю кебек эшләрне Шаймарданов Исмагил үз семьясы белән эшли. Кассирлык хезмәтен Низаев К. алып бара.

Бу мәктәп бинасы 1932 нче елда эксплуатациягә бирелә. Укытучылар саны 12 гә җитә, балалар саны 250 дән артык була. Шул хисапка класслар да арта. Мәктәп участогына иске кулак йортлары да китереп салына бара. 1938-1941 нче елларда мәктәп каршында 2 га җирдә бакча утыртыла. 10 - 12 га якын ярдәмче хуҗалыкта җир эшкәртеп икмәк чәчелә, 3 баш сыер була. Балалар өчен кайнар аш бирелә.



Беренче елларны җәй көне балалар берәр айга Көтмәс буена лагерьга бара торган булалар.

Мәктәп директоры Яппаров Габдулла ага 1942 нче елның августында озак авырудан соң операция ясата, операция уңышсыз чыга һәм ул вафат була. Ул Кадыбаш авыл зиратына күмелә.

Сугыш чорларында мәктәп нык үзгәрә. 1942 нче елның сентябреннән 1943 нче елның сентябренә кадәр мәктәп директоры булып Гумерова Маһия эшли. 1943 нче елның 1 сентябреннән 1944 нче елның 1 нче сентябренә кадәр Федотова Пелагея эшли. Бу чорда уку-укыту эше авыр була. Чөнки Бөек Ватан сугышының авырлыгы авылда яшәүчеләргә дә, шул исәптән укучыларга да, бик нык кагыла. Язу өчен иске китаплар, кара урынына мунча корымнары, акбур урынына яндырылган сөякләр файдаланыла. Шуңа карамастан, 1941-1942 нче уку елында мәктәпне 25 укучы, 1942-1943 нче уку елында 24 укучы, 1943-1944 нче уку елында 28 укучы, 1944-1945 нче уку елында 26 укучы тәмамлап чыга.

1944 елның сентябреннән Красный Бор исполкомы тәкъдиме белән, Красный Бор РОНО мөдире булып эшләүче, 1903 нче елда  Пермь өлкәсендә туган, Иске Сләк авылына килеп урнашкан, Хәлимов Гали директор итеп җибәрелә. Ул 1947 нче елга кадәр эшли.

Бу чорда мәктәпнең аты була. 1 га мәйданда солы чәчелә. Мәктәп хуҗалыгында үзгәрешләр булмый.

1947 нче елдан РОНО билгеләве буенча (Мөслим районы гражданы, 1908 елда туган, КПСС члены) Иманаев Александр Иманаевич директор булып килә.Бу вакытта балалар саны арта. Шуңа күрә Гали, Алга, Касай балалары өчен интернат бинасы салдыра, мәктәп әйләнәсен киртәли, бинаның түбәсенең бер өлешен тактадан яңарта, 2 га бакча участогына яңадан агачлыр утырта башлый. Иманаев 1954 елның көзенәчә эшләп укытучы булып кала.

1952-1953 нче уку елында мәктәп каршында 1-4 класс, 5-7 класслар ачып кичке мәктәпләр оештырыла. Ләкин йөреш түбән була.



1954 елның августыннан мәктәп директоры булып, раисполком председателе ярдәмчесе булып эшләүче, Багаутдинова Гайшә эшли башлый (1909 нчы елда туган). Ул 1954 елдан 1965 елга чаклы эшли. Бу чор эчендә мәктәп җиләк-җимеш бакчасы киңәйтелә. 1961-1962 уку елында мәктәп 8 еллык итеп үзгәртеп корыла. Беренче мәртәбә 8 классны 22 укучы тәмамлап чыга. Бу вакыт эчендә мәктәпкә техник средстволар алалар. 1961 елда мәктәп киноаппарат, магнитофон, фугавальный станок, 1963 елда радиоприемник сатып алына, 5 тегү машинасы алына.1965 елда Багаутдинова пенсиягә чыга, мәктәп директоры булып Арсланова Рәхилә кала (1965-1968 еллар).

Бу дәвердә 3 класслы бина салынып бетә һәм файдалануга тапшырыла. 40 урынлы интернат бинасы төзелә башлый. Кичке мәктәп юлга салын, 9 ,10 , 11 нче класслар ачыла.1967-1968 елында 14 кеше 11 классны тәмамлап чыга